ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин пр,17йорт,Актаныш ав., 423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
08.04.2020

КАРАР
№ ПР-65

Социаль ярдәмнең аерым чараларын бирү срогын озайту турында

Яңа короновирус инфекциясе таралу куркынычын минимальләштерү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 2013 елның 23 сентябрендәге ПР-657 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 18 декабрендәге ПР-316 номерлы карары белән билгеләнгән, дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен өстәмә компенсация алучы гражданнарга җан башына уртача керем 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә,түләү чоры 2020 елның 30 сентябренә кадәр тәмамлана торган социаль ярдәм чараларын, аларны алуга гаризаны кабат тапшырмыйча, 2020 елның 1 октябренә кадәр озайтырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев